МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.03.2021 г. Казань № 439

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 07.06.2019 елдагы № 1167 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 07.06.2019 елдагы № 1167 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру Тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

пункт 11 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Спортчыларның сәламәтлеге торышына системалы контроль үз эченә беренчел һәм даими медицина тикшерүләрен, шул исәптән тирәнтен медицина тикшерүләрен (алга таба-тирәнтен медицина тикшеренүләр УМО) үткәрүне, функциональ халәткә мониторинг һәм коррекция, этаплы һәм агымдагы медицина тикшерүләрен, табиб-педагогик күзәтүләрен ала һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 23.10.2020 елдагы № 1144н боерыгы белән расланган Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга (шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм үткәргәндә) медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру Тәртибе нигезендә, шул исәптән спорт әзерлеге узарга, оешмаларда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яки) «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының норматив сынауларын (тестларын) үтәргә теләүче затларны медицина карау тәртибен дә кертеп, (алга таба – Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибе), әлеге Тәртипкә Кушымта №3 каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла»;

№3 каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла»;

Тәртипкә Кушымта №3 пункт 4 редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы спорт федерацияләре медицина оешмаларына федерациянең рәсми бланкында алдагы елның 1 декабренә кадәр спорт төрен (спорт дисциплинасын), составны, яшь төркемнәрен, спортчыларның башлангыч санын һәм тирәнтен медицина тикшерүләре уздыру срокларын күрсәтеп, Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру тәртибе нигезендә, башлангыч җыелма гаризаларны тапшыра».

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы А.Р. Абашев

Е.В. Никитина
8(843)231-79-63